Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Солтан авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 17**

Олы Солтан авылы 2016 елның 4 октябре

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча Олы Солтан авыл җирлеге территориясендә җирле референдум билгеләү турында

2002 елның 12 июнендәге “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсенә, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законының 20 маддәсенең 1 өлеше 1 пунктына, 2004 елның 24 мартындагы “Җирле референдум турында” 23-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законының 12 маддәсенең 1 пункты “в” пунктчасына, 18 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Солтан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 11 маддәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 3 октябрендәге “Референдум үткәрү инициативасы турында” 14 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге “Референдум үткәрү инициативасы турында” 16 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге территориясендә 2016 елның 20 ноябренә җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарылучы түбәндәге сорауны расларга:

“Яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге территориясендә теркәлгән балигъ булган, уку йортларының көндезге бүлекләрендә укучы студентлардан гайре, һәрбер кешенең 2017 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертүенә һәм җыелган средстволарның түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә:

- Олы Солтан авылында Р.Шәрәфеев урамы юлларына түшәү өчен вак таш сатып алырга һәм юлга түшәргә;
- Яңа Солтан авылында 4500 сумга чишмә ремонтларга;
- Гобәй авылына насос алырга;

- ЯңаСолтан авылында тоташтыручы буаны (күперне) ремонтларга

Сез ризамы?

ӘЙЕ ЮК”.

3. Әлеге карарның рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керүен билгеләргә.

4.Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Солтан авылы, Р.Шәрәфиев урамы, 12 нче йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Солтан авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Сөнгатуллин

СОВЕТ
БОЛЬШЕСАЛТАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1634000725
ОЛЫ СОЛТАН
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ